**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Балыклы-Чукаевского**
**сельского поселения**
**Рыбно Слободского**
**муниципального района**

**Центральная ул., дом 8,**
**с. Балыклы-Чукаево, 422655**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Балыклы-Чүкәй**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

**Үзәк урамы, 8 нче йорт,**
**Балыклы-Чүкәй авылы , 422655**

**Тел.: (8-4361) 26357 факс: (8-4361)26357, эл.адрес: Blc.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.03.2019 Балыклы-Чүкәй авылы №3

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүләрнең административ регламенларын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль (үзидарәлек) хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында” 96пи номерлы карарын исәпкә алып КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль милектәге торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта № 1).

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта № 2).

1.3. Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, гамәлдән чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта №3).

1.4. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта № 4).

1.5. Васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта № 5).

1.6. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта № 6).

1.7. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын (Кушымта №7).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 17, карарларын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 йорт; Иске арыш авылы, Үзәк урамы, 23а йорт; Керэшен Казысы авылы, Титов урамы, 11б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй
авыл җирлеге башлыгы А.М.Нуртдинова